ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 г. № 58

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта).

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН МКУ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 29 нчы гыйнвар
58 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган агач һәм куак кисүгә, ябалдашлауга, саклап калуга яисә утыртуга карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (22 нче кушымта):

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» баганасаның 2.6. пунктына икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүмат.».

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 ноябрендәге 733 номерлы карары белән расланган тышкы мәгълүмат чараларын (паспортларны) урнаштыру эскизы проектын килештерү (гамәлдән чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктына егерме җиденче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7. Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүмат.».